РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

04.08.2026 № 96-п

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы кешеләренең массакүләм була торган урыннарын тикшерү исемлеген раслау турында (өстәмәләр белән)

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2026 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектлар (территорияләр) һәм кешеләр күпләп була торган урыннарның һәм объектларының (территорияләрнең) террорчылыкка каршы яклануына карата таләпләрне раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары нигезендә һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлеге паспортлары рәвешләрен үтәү өлешендә карар бирәм:

1. Расларга:
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы кешеләренең массакүләм була торган урыннарын тикшерү исемлеген (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Л. Р. Шакирҗановка кешеләр массакүләм була торган урыннар исемлегенә яңа кертелгән объектның - 422430, ТР, Буа районы, Карлы авылы, Буа - Алан ур, 3нче җир кишәрлеге адресы буенча урнашкан сулык ярында актив ял итү зонасы булган пляжның документларын «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланылырга тиешле кешеләр күпләп була торган урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлек паспортлары формаларын раслау турында» РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары таләпләре белән рәсмиләштерү эшен оештырырга.
3. Буа муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы кешеләренең массакүләм була торган урыннарын тикшерү исемлеген һәм графигын раслау турында» 2024 елның 22 гыйнварындагы 6-п номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар аңа имза салынган көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы Р.Р. Камартдинов

Татарстан Республикасы

Буа муниципаль районы
Башлыгының

04 август 2026 ел 96-п
номерл карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы кешеләренең массакүләм булу урыннары исемлеге

| № т/б | Объект исеме | Объект урнашуын урынның  фактагы адресы |
|---|---|---|
| 1. | «Яшьләр» паркы | 422430, РТ,  Буа шәһәре,  Космовский урамы, 91 кишәрлек |
| 2. | «Үзәк» парк | 422430, РТ, Буа шәһәре К.Маркс урамы, 44 кишәрлек |
| 3. | «Мирас» яшьләр үзәге | 422430, РТ,  Буа шәһәре,   Камиль Зыятдинов урамы, 6й. |
| 4. | Сулык ярында актив ял итү зонасы булган пляж | 422430, ТР, Буа районы, Карлы авылы,  Буа-Алан урамы, 3А җир кишәрлеге |